| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

с. Шланга

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№3/3 2020 ел 3 нче ноябрь

"Җир салымы турында" гы
карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 15 ноябрендәге 45/4 номерлы карарының 4 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«узган чордан соң килүче икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

«елның 5 февраленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен, «Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясында билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән (халыкка игълан ителгән көннән) бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Шланга авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Шланга авыл җирлеге башлыгы
Чүпрәле муниципаль районы
Татарстан Республикасы: И.И.Якупов